КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 15 август г.Казань № 835

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы коллегиясе составын раслау турында» 2019 ел, 28 гыйнвар, 49 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы коллегиясе составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы коллегиясе составын раслау турында» 2019 ел, 28 гыйнвар, 49 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 2 июнь, 459 нчы, 2021 ел, 21 гыйнвар, 14 нче , 2021 ел, 26 апрель, 285 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы коллегиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

коллегия составына Баһаветдинов Альберт Шамил улын – «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең «Су спорт төрләре сарае» укыту-спорт комплексы директорын, Татарстан Республикасының спорт ветераннары советы рәисен кертергә (килешү буенча);

Бариев Марат Мансур улы вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Олимпия советы» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе, «Татарстан Республикасы спорт гимнастикасы федерациясе» төбәк иҗтимагый оешмасы президенты (килешү буенча)»;

Борһанов Рәфис Тимерхан улы вазыйфасы атамасында «ректор вазыйфаларын башкаручы» сүзләрен «ректор» сүзенә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин